**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района Республики Татарстан**
**Совет города Арск**
**422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

# КАРАР

**« 25 » октябрь 2021 ел** **№ 4**

**Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясын гамәлгә ашыру максатларында «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 24 ноябрендә 16 сәг. 00 минутта Арча районы, Күпербаш авылы, Мичурин урамы, 10 нчы йорт адресы буенча билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 24 ноябрендә 17 сәг. 00 минутта Арча районы, Күпербаш авылы, Мичурин урамы, 10 нчы йорт адресы буенча билгеләргә.

3.Торак пунктта яшәүчеләрне исемлек буенча бүлүне территориаль билге буенча башкарырга.

1 нче этап: Яшьлек, Яр буе, Үзәк, Тынычлык урамнарында яшәүчеләр;

2 нче этап: Мичурин, Свердлов, Киров, Мәктәп, Татарстан урамнарында яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 80 яшьтән өлкәнрәклләрдән һәм 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Зират коймаларын ремонтлау һәм буяу, тирә - юнен төзекләндерү (материаллар сатып алу, эшләр өчен түләү)?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. Арча муниципаль районы Күпербаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Арча шәһәре башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны гражданнар күпләп җыела торган урында мәгълүмат стендында (Күпербаш авылы, Мичурин урамы, 10 йорт), интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы «Совет города Арск» И.Г.Нуриев